РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

12.12.2023 ел №220

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының кайбер карарларының үз көчен югалтуын тану турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге №131-ФЗ, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы №25-ФЗ Федераль законнар, «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында» Татарстан Республикасы Кодексының 16.1 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2023 елның 16 ноябрендәге «Регистрда муниципаль норматив хокукый актлар мониторингы турында» №09/13-09/5760 хатын үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

- «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләрнең яллаучы (эш бирүче) вәкиленең коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә (сәяси партиядән тыш) бердәнбер башкарма орган сыйфатында түләүсез катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәтен алу тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2017 елның 16 августындагы №108 карары;
- «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләрнең яллаучы (эш бирүче) вәкиленең коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә (сәяси партиядән тыш) бердәнбер башкарма орган сыйфатында түләүсез катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәтен алу тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2017 елның 16 августындагы №108 карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан

Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2022 елның 28 декабрендәге №155 карары.

2. Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында бастырып чыгарырга (parvo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Чирмешән муниципаль районы Башлыгы,
Татарстан Республикасы Чирмешән
муниципаль районы Советы рәисе Р.Т. Айбатов